УДК 82.512.1-131:398.22

***Л.Х. Мөхәммәтҗанова,***
***Г.Р. Хөсәенова***

## ТАТАР ЭПОСЫНДА РОМАНИК ТӨР ДАСТАННАР

Статья посвящена теме взаимосвязи между национальным историко-культурным процессом и жанровыми особенностями словесного творчества татар. Авторы апробируют термин «романический» по отношению к стадиально новому эпосу – дастанам с любовной тематикой, популярных среди татар вплоть до начала XX в., поднимают вопрос о необходимости выявления места и роли татарских романических дастанов в системе фольклорных и литературных жанров.

**Ключевые слова**: дастан, романический, тематический, фольклор, литература, сюжет, жанровая разновидность, традиционный.

Татар халкы гомер-гомергә китаплы халык булган. Язу культурасына, күп гасырлык бай язма мираска ия булуы аның фольклорына да тәэсир итми калмаган. Иң беренче чиратта нәкъ менә шушы сәбәп татар халкында дастан жанрының язма иҗат булып формалашуын тәэмин иткән. Мондый дастаннар шул ук фольклор традицияләрен язмада дәвам итүләре, Идел буе татарларына хас җирле эпик үзенчәлекләр белән бергә, башка халыклар рухи мирасын гасырлар буе саклап килеп, безнең көннәргә китереп җиткерүләре белән кыйммәт.

Вариантларының күплеге, актив таралышы һәм халык арасында яратып укылуы җәһәтеннән татар дастаннары арасында романик характердагылары әһәмиятле урын алып тора. Болар – Таһир белән Зөһрә, Йосыф, Сәйфелмөлек, Ләйлә белән Мәҗнүн, Шаһсанәм һәм Гариб, Бүз егет һ.б. турындагы мәшһүр сюжетларга иҗат ителгән әсәрләр. Мондый истәлекләрнең үз чорында гаять популярлыгын эмоциональ-маҗаралы әсәрләргә халыкта заманына күрә зур ихтыяҗ булу белән аңлатырга мөмкин.

Романик дастан борынгы төрки һәм фарсы әдәбиятындагы атаклы поэмалар белән тыгыз бәйләнгән. Башкача әйткәндә, бу – индивидуаль язма иҗат, әдәбият белән үтә җитди керешкән өлкә. Фольклорның башка жанрлары (әйтик: миф, әкият, бәет, мөнәҗәт, риваять, афористик һәм йола фольклоры) янәшәсендә дастан жанрының төп хасияте дә нәкъ менә шунда. Татарларда мондый әсәрләр – Урта гасырлардан Яңа чорга күчү чорыннан алып, XX гасыр башынача дәвердә язма әдәбият составындагы иң продуктив иҗат төре.

Урта гасырлар иҗат методы бер үк сюжетның төрле милли версиядә эпик әсәрләр буып таралуын тәэмин иткән. Шушындый «күчмә» сюжетлар, әлбәттә, Идел буе татарларына да килеп җиткән. Алар биредә җирле

традицияләргә туры килә торган яңа яңгыраш алганнар, әдәби-мәдәни процесска фольклор стилендә кушылып киткәннәр. Идел буе татарларында дастаннар кульязмалар рәвешендә дә таратылганнар, халыкта сөйләмә формада да билгеле булганнар, басма китап дәверендә исә алар аерым китаплар булып та басылып чыкканнар.

XVII йөз урталарыннан соң, сәяси вазгыятьнең кырысланып яки йомшарып китүенә бәйле рәвештә, романик характердагы дастаннар халык тарафыннан яратып укылган. Татар романик дастаннары нигездә авторы-күчерүчесенең исеме белән йөри. Романик дастаннар – татар эпосының язма фольклор традициясеннән индивидуаль авторлыкның аерылып чыгу этабын да күпмедер дәрәҗәдә үз эченә алган стадиаль иң соңгы төре.

Романик китаби дастаннар белән Борынгы һәм Урта гасыр әдәби әсәрләре һәм шул ук сюжетка корылган традицион (көй-сүз әйтеп башкарыла торган) эпик текст арасында төгәл чикне билгеләү гаять авыр. Иҗатка хирыс шәхесләр мәгълүм сюжетларга, дастаннар язу белән бергә, оригиналь әсәрләр иҗат итү белән дә шөгыльләнгәннәр. Мәсәлән, татар шагыйре Әхмәтҗан Тубылиның, йөзләгән шигырь һәм дини-фәлсәфи характердагы прозаик әсәрләр авторы булуы белән бергә, мәгълүм сюжетларга дастаннар да иҗат иткәнлеген беләбез. Мондый төр иҗат белән шөгыльләнүчеләр каләмендә фольклор стиле гадәттә үтә җиңеллек белән әдәби традицияләргә үрелеп китә, шуңа да романик дастаннар дигәндә аларга гына хас чик сызыгын тотып алу һәм аерып чыгару җиңел эш түгел.

Мәхәббәт темасына язылган, берничә вариантта таралган уртак сюжетлы әсәрләр романик дастаннар төркеменә керә. Бу төркем дастаннар өлешчә шартлы рәвештә «романик» термины белән билгеләнә. Күләме һәм эчтәлеге ягыннан мондый дастаннарның материалы Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятларында барлыкка килгән роман жанрын колачлый, әмма һич тә роман жанрының бөтен хасиятләрен дә сакламый. Роман жанры тематик (автобиографик, хәрби, детектив, документаль, мәхәббәт, интеллектуаль, тарихи, сәяси, маҗаралы, сатирик, сентименталь, иҗтимагый, фантастик, фәлсәфи һ.б.) һәм структур (шигъри роман, роман-памфлет, роман-сага, роман-кыйсса, роман-фельетон, эпистоляр роман һ.б.) яктан шактый күп төркемнәргә бүленсә, романик характердагы дастаннар дип карала торган татар телле әсәрләрнең тематикасы шактый чикле: аларның һәркайсы, гадәттә, бер генә теманы ача – ике гашыйкның мәхәббәт тарихын бәян итә. Бу төр дастаннарны төзелеше белән дә артык катлаулы дип әйтеп булмый. Шул ук вакытта романик дастаннар, роман жанры (тарихи романнардан кала) кебек үк, шәхси тормыш вакыйгаларына нигезләнә, гади кешеләр язмышын тасвирлый. Романик китаби дастаннар бигрәк тә Яңарыш әдәбиятында шәхси тормыш эпосы буларак

мәйданга чыккан романнарга якын торалар, адәм балаларының шәхси омтылышларын, шатлык-кайгыларын, уңыш-фаҗигаләрен тасвирлыйлар.

Яңарыш чоры романында шәхеснең кичерешләре һәм гамәлләре иҗтимагый мотивлаша, чөнки яңа җәмгыятьтә шәхси һәм иҗтимагый тормыш – кеше яшәешенең бер дәрәҗәдәге яклары. Мондый әсәр үзәгенә үзенең аң дәрәҗәсе, үзаңы белән башкалардан аерылып, җәмгыятьнең әдәби сурәтләнештәге хәл-халәте белән каршылыкта торучы шәхес куела. Роман жанрындагы әсәрдә «бер язмышта, бер кеше тормышы мисалында шул чор өчен иң характерлы шартлар әдәби гомумиләштереп тасвирлана, тормышның ниндилеге бер образ итеп җыеп сурәтләнә» [Әдәбият белеме сүзлеге, б. 167]. Роман бүгенге чынбарлыкны якындагы үткән белән бәйли.

Ә романик дип билгеләнгән дастаннарда вакыйгалар һәрвакыт ерак үткәнгә карый, биредә роман жанрына хас тенденциозлык, әсәрдә шәхси тормыш мисалында тормыш-яшәеш мәгънәсен ачарга, яшәү рәвешен чагылдырырга омтылу кебек әдәби концепциянең булуы артык сизелми. Романик китаби дастаннар аерым бер темаларны һәм традицион мотивларны кабатлый, бәхетсез тәгалләнә торган сюжеты белән дә, кайбер геройларның чынбарлыкта яшәгән шәхесләргә барып тоташуы ягыннан да алар гаять мавыктыргыч.

Дастаннарның романик төркемгә карый торганнары, билгеле бер тема-мотивларны үстерүләре һәм текст эчтәлегендә романтик иҗатка хас шәркый кануннар, кайбер эстетик алымнар, бизәклелек кулланылу ягыннан романтизм (нем. *romantic,* фр. *romantisme,* ингл. *romantism*) әдәби юнәлешенең Көнчыгыш романтик иҗат тибына да бик нык якын торалар. Романик дастанарда романтизм иҗат юнәлешенә хас булган кайбер сыйфатлар күзгә чалына, әйтик, хисләр байлыгы, тәэсирлелек, геройны идеаллаштырып сурәтләү, рухи башлангычка өстенлек бирү. Романик дастаннарның әдәбияттагы роман жанры һәм романтизм юнәлешенең икесенә дә берьюлы һәм төрле яклап тартылуы кайвакыт мондый әсәрләргә карата «романтик дастаннар» дигән билгеләмә кулланырга мөмкинлек бирә. Фольклор белән әдәбият арасында торган, халыкта берничә вариантта һәм версиядә таралыш алган, мәхәббәт темасына багышланган уртак сюжетлы дастани әсәрләрне әдәбият һәм фольклор галимнәре романик дастаннар дип тә, романтик дастаннар дип тә атыйлар. Шулай да дастани эпоска бай халыкларда очрый торган мондый төр иҗатка карата «романик дастаннар» дигән термин куллану «романтик дастаннар»га караганда ешрак очрый. Е.М. Мелетинский, П.А. Гринцер, В.М Жирмунский, С.Ю. Неклюдов кебек галимнәр төрле халыкларның мондый категориядәге эпик әсәрләре турында сүз барганда «романик» терминына өстенлек бирәләр [Мелетинский, 1986, с. 141, 143, 145, 167 и др.; Гринцер, с. 3–44;

Жирмунский, с. 19, 643; Неклюдов, с. 251–267].

Тематик принципка һәм романтизм методына хас кайбер сыйфатлары булуга карап, татар дастаннарының мондый төрен романтик дастаннар дип атау хата булмаса да, традиционлык һәм индивидуальлек җәһәтеннән әдәби иҗатка, китапка бик нык якын торулары сәбәпле, мондый әсәрләрнең эчтәлеген «романик» термины төгәлрәк ача кебек, шуңа күрә, атаклы галимнәр фикеренә кушылып, роман жанры чалымнары кергән, идея-эчтәлегендә романтизм юнәлешенең бер агымына хас сыйфатлар чагылыш тапкан, мәхәббәт тематикалы дастаннарны «романик дастаннар» дип атау дөресрәк булыр.

Татар халык иҗатының романик дастаннары төркемендә төп тема, чыннан да, – мәхәббәт. Борынгы һәм Урта гасыр Көнчыгыш әдәбияты традициясендә илаһи мәхәббәткә дан җырлаган әсәрләр татар дастаннарның иң зур өлешен алып тора [Мухаметзянова]. Романик дастаннар һәркайсы диярлек үзләренең чагыштырмача күләмле булулары белән аерыла. Татар романик китаби дастаннарын Урта Азиядә мәгълүм «Рөстәмхан», «Сәят-Хәмра», «Асли-Кәрәм» һ.б. дастаннар кебек саф романик әсәрләр дип әйтеп булмый. Татар телле дастаннар алардан шигъри эшләнешенең күбесенчә тезмә аралаш чәчмә булулары, күләменең чагыштырмача кечкенәлеге, сюжет җепләренең артык катлауланмыйча, бер я берничә сызыктан гына гыйбарәтлеге, төгәл структуралы булулары, милли җирлек чагылыш тапкан сюжет үзенчәлекләре һ.б. сыйфатлары белән аерылып торалар. Идел буе татарлары романик дастаннары нигездә барысы да китап стиленә тартыла. Бу төркем дастаннарда әдәби сюжетлар, әдәбиятның поэтик формалары фольклор стилендә үзләштерелгән. Персонажлар сөйләмендә дә «тере» башкарылуга хас билгеләргә караганда әдәби телгә якын нейтраль тел өстенлек итә.

Идел буе татарлары язма фольклорындагы мәхәббәт дастаннарында, шул ук сюжетка жанрның «тере» традицион төре белән чагыштырганда, әлбәттә, динамикалык, башкарудагы киң диапозон, телдән хикәяләүдә очрый торган пафос инде юылган, шигырь төзелешендә халык стиле буларак кулланылып килгән силлабикага нигезләнү дә бик нык кимүгә йөз тоткан. Романик дастаннарда кайвакыт героика чалымнары да чагылып китә. Әйтик, «Сәйфелмөлек», «Бүз егет», хәтта «Ләйлә белән Мәҗнүн»дә дә бу ачык күренә. Ә менә атаклы «Түләк», гәрчә ул мәхәббәт дастаны булса да, үзенең архаиклыгы белән һәм алыплар турындагы хикәятләргә охшашлыгы ягыннан күбрәк каһарманлык дастаннары төркеменә якын.

Романик дастаннар, каһарманлык дастаннары кебек үк, төп герой исеме белән аталып йөртеләләр, ягъни әсәр эчтәлеген аның исеме үк әйтеп тора. Төп эчтәлеген мәхәббәт тарихы алып торган романик дастаннар парлы исемнән гыйбарәт: «Таһир белән Зөһрә», «Ләйлә белән Мәҗнүн»,

«Шаһсәнәм һәм Гариб», «Хурлуга һәм Һәмра» һ.б.

Мәхәббәт тарихын бәян итә торган дастаннарыбызның янә бер үзенчәлеге дастан вакыйгаларының фаҗига белән тәмамлануыннан гыйбарәт. Бәхетле кавышу мотивы фәкать «Йосыф китабы»нда һәм «Хурлуга белән Һәмра»да гына сакланган. Башка төрки халыкларда гашыйкларның бергә булулары белән тәгәлләнә торган «Шаһсәнәм һәм Гариб», «Сәйфелмөлек» кебек дастаннарның татар версиясендә дә әлеге фаҗигале үлем идеясе киң таралган. Романик китаби дастаннарыбызда трагик мәхәббәт тематикасының популярлыгы турыдан-туры борынгы гарәп риваятьләреннән килә. Әйтик, татар халкында «Ләйлә белән Мәҗнүн» сюжеты бик киң таралган булган, мәхәббәт дастаннарының фаҗигале бетеменә бу әсәр зур йогынты ясаган. Шулай ук XIII–XV йөзләрдә төрки халыклар иҗатында киң таралган «Кузы Күрпәч белән Баян-Сылу» дастанының да тәэсире зур булган. Әсәрне трагик ноталарда тәмамлау дастанны тагын да тәэсирлерәк, эмоциональрәк ясаган, шуның белән укучыны ныграк җәлеп иткән. Бу җәһәттән Казан татарлары романик дастаннары, күпмедер дәрәҗәдә, Е.М. Мелетинский тарафыннан Көнчыгыш новеллалары дип билгеләнгән язма истәлекләргә, аерым алганда «Мең дә бер кичә»гә якын тора. Е.М. Мелетинский мәхәббәт темасы өстенлек иткән романик новеллаларда егет-геройның, кагыйдә буларак, бик пассив, самими, әмма үтә намуслы, вөҗданлы, ә кыз-геройның исә актив һәм инициатива күрсәтүчән булуының гомуми планда алга чыгуына игътибарны юнәлтә [Мелетинский, 1990, с. 34]. Татар романик дастаннарында аңлы рәвештә холыкны тасвирлау турында сүз алып барырга бик чикле булса да, һәр заман өчен таныш зыялылык, гомуми олы хисләр пәрдәсе артында геройларны аерым бер сыйфатларыннан танып алырга мөмкин. Татар халык дастаннарында кыз-герой хәтта үзенең зирәклеге, тапкырлыгы, кыюлыгы, сөйгәненә карата демократик холкы белән Көнчыгыш новеллаларыннан, шулай ук дастаннарның Көнчыгыш халыклардагы версияләреннән аерылып тора.

Татар романик дастаннары Көнчыгыш әдәбияты тәэсирендә туганнар һәм озак гасырлар дәвамында шул әдәбият йогынтысында формалашканнар, шул сәбәпле аларда Борынгы һәм Урта гасыр Көнчыгыш әсәрләреннән килә торган консервативлык традицияләре үзен бик нык сиздерә. Боларда заман таләпләрен канәгатьләндерерлек дөньявилык, Европа мәдәниятенә, әдәбиятына, фәненә омтылыш идеяләре бөтенләй юк. Әмма татар әдәбиятын һәм мәдәниятен борынгыдан азыкландырып килгән Шәрык мәдәнияте һәм аның аша романик дастаннарыбызга үтеп кергән идеяләр, стиль-үзенчәлекләр билгеле бер чорга кадәр милләтебезнең табигатенә гаять ярашлы булган. Романик дип билгеләнгән төргә керә торган әсәрләрнең татарларда XX гасыр башынача

популярлыгын шул сәбәп белән аңлатырга мөмкин.

Романик китаби дастаннарның һәркайсында әдәбият кануннары белән фольклор кануннары табигый үрелештә чагылыш таба. Бу төр әсәрләр – гашыйклык дастаны гына түгел, ә «гомумән мәхәббәт, кешенең бөтен барлыгын биләгән олы хис» [Татар халык иҗаты, б. 23] турындагы дастан. Мәхәббәттән дә зуррак көчнең булмавы идеясе романик дастаннарның һәрберсендә үтә җете кызыл җеп булып сузылган. Мондый дастаннар Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятына хас суфичылык идеяләреннән дә азат түгел. Бу төркемгә керә торган дастаннарда китап традицияләре фольклор үзенчәлекләре белән бик тыгыз аралашкан. Татар халкының романик дастаннары Көнчыгыш романтик иҗат методыннан бик күп сыйфатлар алган. Шул ук вакытта бу төр дастаннарыбыз татар әдәбиятында XX йөз башында иҗат методы буларак, роман жанры формалашуга да йогынты ясап, аның үсешендә мәгълүм бер баскыч ролен дә үтәгәннәр. Димәк, романик характердагы дастаннарыбызның татар дастаны үзенчәлекле специфик бөтен барлыкка китерүдә бик зур роль уйнавы бәхәссез.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар халкында Урта гасыр иҗат методы традициясендә әсәрләр язу бик киң таралган була. Бу метод мәгълүм сюжетка корылган мәшһүр бер әсәргә ияреп язу, аны тулысынча яки өлешләп тәрҗемә итү, шул сюжеттан илһам алып, яңа җирлектә өр-яңа әсәр иҗат итү, ул әсәрнең халыкта популярлашып, әллә ничә вариантта таралуы аша туган ядкәрләрдә тормышка ашырылган. Һәрхәлдә татар халкында, аерым алганда Идел буе татарларында, әлеге методның нәкъ менә шундый – чагыштырмача иркен стильдәге юнәлеше өстенлек иткән. Шушы гаять күпкырлы һәм масштаблы күренешнең бер чагылышы булып, татар халык иҗатында «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Таһир белән Зөһрә» кебек популяр дастаннар барлыкка килгән. Халыкта борынгы чорларда ук киң таралыш алган мондый сюжетлар татарларда XX гасыр башынача актив яшәгән. Татар телендә ярым әдәби, ярым фольклор текстларны төзегән иҗатчы-күчерүчеләр китап теленә, китаби гыйбарәләргә һәм образларга мөрәҗәгать иткәннәр, шул рәвешле романик дастаннарда фольклор катыш әдәби стиль ныгыган. Татар романик дастаннары эпик фольклорның зур өлешен алып торуы, әдәби процесста актив катнашуы ягыннан гаять әһәмиятле, махсус өйрәнелергә хаклы өлкә.

**Әдәбият**

*Гринцер П.А.* Две эпохи романа (вводная статья) // Генезис романа в литературах Азии и Африки. Национальные истоки жанра. М.: Наука, 1980. С. 3–44.

Әдәбият белеме сүзлеге. Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 163.

*Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л.: Наука, 1974. 728 с.

*Мелетинский Е.М.* Введение в историческую поэтику эпоса и романа. М: Наука, 1986. 320 с.

*Мелетинский Е.М.* Историческая поэтика новеллы. М.: Наука. Главная редакция восточной литературы, 1990. 275 с.

*Мухаметзянова Л.Х.* Тематическая классификация татарского эпоса: романические и героические книжные дастаны // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота. 2014. № 6 (36). Ч. 2. С. 161 – 163.

*Неклюдов С.Ю.* От эпоса к роману // Неклюдов С.Ю. Героический эпос монгольских народов. М.: Наука, 1984. С. 251 – 267.

Татар халык иҗаты. Дастаннар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 384 б.

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,***
*филология фәннәре докторы, доцент,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать*
*институтының халык иҗаты бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*
*e-mail: lilmuhat@mail.ru*

***Хөсәенова Гөлнира Рәзиф кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге аспиранты*
*e-mail: gulnira2010@yandex.ru*